РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«6» декабря 2023г. г. Альметьевск №264

**Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2018 елның 31 маендагы 244 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты турында нигезләмә хакында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 2 ноябрендәге 517-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 4 августындагы 449-ФЗ номерлы федераль законнар, «Табигый дәвалау ресурслары, дәвалау-савыктыру урыннары һәм курортлар турында» Федераль законга, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану хакында» 2023 елның 4 августындагы 469-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм хокукый мониторинг нигезендә,

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2018 елның 31 маендагы 244 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты турында нигезләмә хакында»гы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2019 елның 16 декабрендәге 343 номерлы, 2021 елның 11 мартындагы 40 номерлы, 2021 елның 17 июнендәге 58 номерлы, 2022 елның 20 апрелендәге 144 номерлы, 2023 елның 29 мартындагы 212 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. карарның 1 нче кушымтасының 2 бүлегендә «район Башкарма Комитетының вәкаләтләре» :

1.1.1. 2.2 пунктның 3 пунктчасы тугызынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- җирле әһәмияттәге аеруча саклана торган табигый территорияләрне куллану һәм саклау өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыра;»;

1.1.2. 2.2 пунктның 3 пунктчасын түбәндәге эчтәлектәге ундүртенче абзац белән тулыландырырга:

«- әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыян объектларын ачыклауны гамәлгә ашыра һәм муниципаль район милкендәге җир кишәрлекләре чикләрендә урнашкан территорияләргә карата мондый зыянны бетерүне оештыра;»;

1.1.3. 2.2 пунктының 7 пунктчасы унбишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- балалар һәм яшьләр белән эшләү буенча җирлекара чаралар оештыра һәм гамәлгә ашыра, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнаша, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшли һәм гамәлгә ашыра, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программалар эшли һәм гамәлгә ашыра ;»;

1.1.4. 2.3 пунктның өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«-муниципаль хокукый актларны халыкка җиткерү, муниципаль берәмлек халкына рәсми мәгълүмат җиткерү өчен массакүләм мәгълүмат чарасын һәм (яисә) челтәр басманы гамәлгә куя;»;

1.1.5. 2.4 пунктындагы 3 пунктчасының унберенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- җирле әһәмияттәге махсус сакланылучы табигать территорияләреннән файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыра;»;

1.1.6. 2.4 пунктының 1 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле сигезенче абзац өстәргә:

«- балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыра һәм гамәлгә ашыра, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнаша, яшьләр хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшли һәм гамәлгә ашыра, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программалар эшли һәм гамәлгә ашыра, җирлектә яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру мониторингын оештыра һәм гамәлгә ашыра;».

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар, 2024 елның 1 сентябрендә үз көченә керүче 1.1.1, 1.1.5 пунктларыннан тыш, рәсми рәвештә басылып чыккач (халыкка җиткерелгәч) үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Н.В. Парфилова).

Муниципаль район Башлыгы — Т.Д. Нагуманов

СОВЕТ АЛЬМЕТЬЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА